# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Физик культура һәм спорт турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала, физик культура һәм спорт системасы эшчәнлеге һәм үсеше өчен хокукый, оештыру, икътисадый һәм социаль нигезләрне билгели.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу

Физик культура һәм спорт өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясендә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында"гы Шартнамәсендә билгеләнгән гомуми принципларга нигезләнә һәм әлеге Закон, физкультура һәм спорт өлкәсендәге бүтән норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

2 статья. Әлеге законнын максатлары һәм бурычлары

Әлеге Закон халык арасында физкультура-савыктыру һәм спорт эшләре алып баруның массакүләм һәм индивидуаль рәвешләрен үстерү өчен шартлар тудыруга, сәламәт тормыш рәвешен раслауга, авыруларны профилактикалауга, кешене физик һәм әхлакый яктан камилләштерүгә юнәлдерелгән.

<u>3 статья.</u> Әлеге законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

физик культура - кешенең физик үсешен, аның сәламәтлеген ныгыту һәм хәрәкәтчәнлеген камилләштерү максатларында культураның җәмгыять тарафыннан барлыкка китерелә һәм файдаланыла торган рухи һәм матди байлыклар җыелмасын тәшкил итүче состав өлеше, социаль эшчәнлек өлкәсе;

физик тәрбия - сәламәт, физик һәм рухи яктан камил, әхлакый тотрыклы яшь буын формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, эшкә сәләтлелекне, иҗат мөмкинлекләрен арттыруга һәм кеше гомерен озайтуга юнәлдерелгән педагогик процесс;

спорт - ярышу эшчәнлеге, кешене ярышларга әзерләүнең махсус практикасы рәвешендә, физик культураның тарихи барлыкка килгән состав өлеше;

физик культура һәм спорт системасы - Татарстан Республикасында халыкны физик тәрбияләү һәм спортны үстерү максатларында эшчәнлекне гамәлгә ашыручы дәүләт һәм җәмәгать оешмаларының җыелмасы;

физкультура (физкультура-спорт) хәрәкәте - социаль хәрәкәткең халыкның физик культура дәрәҗәсен күтәрүгә, дәүләт һәм җәмәгать оешмаларының, гражданнарның физик культураны һәм спортны үстерү буенча максатчыл эшчәнлегенә ярдәм итүне максат итеп куйган социаль хәрәкәт рәвеше;

Татарстан Республикасында олимпия хәрәкәте - кешенең физик һәм рухи камиллегенә ирешү чараларының берсе буларак, спортны үстерүне, халыкара спорт хезмәттәшлеген ныгытуны максат итеп куйган Россия олимпия хәрәкәтенең состав өлеше;

физкультура-спорт берләшмәсе - Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү максатларында гражданнар инициативасы буенча төзелүче иҗтимагый, ихтыярый, үзидарәле, коммерциячел булмаган берләшмә;

физкультура-спорт оешмасы - физкультура-спорт берләшмәсенең физкультура-савыктыру һәм спорт эшләре башкару буенча күмәк эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм үзенең устав максатларына ирешү

йөзеннән әгъзалык нигезендә төзелгән оештыру-хокукый рәвешләреннән берсе;

«Физкультура һәм сәламәтлек» бөтенроссия комплексы - программалар һәм нормативлар бергәлеге - халыкны физик тәрбияләү нигезе;

Бердәй бөтенроссия спорт классификациясе - спорт разрядлары һәм исемнәре бирү нормаларын, таләпләрен, шартларын һәм тәртибен билгеләүче программ-норматив документ;

Бердәй республика спорт классификациясе - спортның милли төрләре буенча разрядлар һәм исемнәр бирү нормаларын, таләпләрен, шартларын һәм тәртибен билгеләүче программ-норматив документ;

һәвәскәр спорт - гражданнарны физик тәрбияләү һәм спортның төрле төрләрендә перспективалы һәм талантлы спортчыларны ачу системасының органик өлеше буларак, күпкырлы массакүләм спорт хәрәкәте;

профессиональ спорт - спорт оешмаларының, спортны үз профессияләре итеп сайлаган спортчыларның һәм тамашачыларның мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү максатында алып барылучы эшкуарлык эшчәнлеге;

спортчы - спорт белән даими шөгыльләнүче һәм спорт ярышларында чыгыш ясаучы зат;

һәвәскәр спортчы (физкультурачы) - үзе сайлаган спорт төре белән яисә физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүче, спорт ярышларында ихтыярый катнашучы яисә Бердәй бөтенроссия спорт классификациясе һәм (яисә) Бердәй республика спорт классификациясе таләпләренә туры килүче разряд нормативларын һәм (яисә) «Физкультура һәм сәламәтлек» бөтенроссия комплексы нормативларын үтәгән спортчы;

югары класслы спортчы - Бердәй бөтенроссия спорт классификациясе һәм (яисә) Бердәй республика спорт классификациясе таләпләре нигезендә спортның кайсы да булса төре белән даими шөгыльләнүче, Россия һәм халыкара спорт ярышларында даими чыгыш ясаучы, кимендә «Россия спорт мастеры» һәм (яисә) «Татарстан Республикасы спорт мастеры» исемнәренә ия булган спортчы;

профессиональ спортчы - спорт белән шөгыльләнү хезмәт эшчәнлегенең төп төре булган һәм спорт ярышларына әзерләнгән һәм аларда катнашкан өчен контракт нигезендә хезмәт хакы һәм башка төрле акчалата бүләк ала торган спортчы;

физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалары - гражданнарга физик күнегүләр һәм спорт белән шөгыльләнү һәм спорт тамашалары уздыру өчен билгеләнгән объектлар;

спорт сәнәгасе - физкультура-спорт һәм туристлык билгеләнешендәге продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы сәнәга предприятиеләре җыелмасы. Мондый предприятиеләр дигәндә махсуслаштырылган комбинатлар, заводлар, фабрикалар һәм фәнни оешмалар, шулай ук үз эшчәнлекләрен, билгеләнгән тәртиптә расланган техник документациягә һәм (яисә) норматив актларга таянып, физкультура-спорт һәм туристлык билгеләнешендәге продукцияне җитештерү лицензияләре нигезендә башкаручы махсуслаштырылмаган сәнәга предприятиеләренең кайбер цехлары аңлашыла.

**<u>4 статья</u>. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәте принциплары**

Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәте түбәндәге принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла:

гражданнарның төрле яшьтәге төркемнәрен тормыш эшчәнлекләренең барлык этапларында физик тәрбияләүнең өзлексезлеге һәм дәвамчанлыгы;

физик культура һәм спорт үсешенең республика программаларын әзерләгәндә һәм тормышка ашырганда барлык гражданнарның да мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның үз сәламәтлекләре һәм физик халәтләре өчен җаваплылыкны танулары;

әлеге закон таләпләренә туры килүче барлык физкультура-спорт берләшмәләренең мөстәкыйльлеген, аларның дәүләт ярдәменә хокукларының тигезлеген тану;

Татарстан Республикасында физкультура-спорт һәм спорт-техник оешмаларны, олимпия хәрәкәтен, физик культура һәм спорт өлкәсендәге мәгариф учреждениеләрен һәм фәнни оешмаларны, шулай

ук спорт сәнәгасе предприятиеләрен финанслауның уңайлы шартларын булдыру.

5 статья. Физик культура һәм спорт үсешенә дәүләт ярдәме чаралары

1. Татарстан Республикасында дәүләт физик культура һәм спорт үсешен тәэмин итә, физкультура (физкультура-спорт) хәрәкәтенә һәм Татарстан Республикасында олимпия хәрәкәтенә ярдәм итә һәм аны түбәндәгеләр буенча тәэмин итә:

физик культура һәм спорт өлкәсендә республика гамәлләрен, шул исәптән спортчыларны Олимпия уеннарында, бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында катнашуга әзерләү гамәлләрен һәм аларда катнашу гамәлләрен Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән ел саен финанслау;

физкультура-спорт оешмаларына һәм спорт сәнәгасе предприятиеләренә дәүләтнең финанс, матди-техник һәм мәгълүмати ресурсларыннан, шулай ук фәнни-тикшеренү һәм техник эшләнмәләрдән, технологияләрдән файдалану өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасы милкендәге физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмаларны тоту;

гражданнарның яшәү урыннары буенча спорт һәм физкультура-савыктыру корылмалары төзү һәм аларны тоту өчен шартлар тудыру һәм шундый корылмалар нигезендә физкультура-савыктыру һәм спорт хезмәтләре күрсәтү;

балалар һәм яшүсмерләр өчен барлык төрдәге һәм типтагы спорт мәктәпләренең, гражданнарның яшәү урыннары буенча клубларның, балалар һәм яшьләр өчен спорт-савыктыру лагерьларының, табиблык-физкультура диспансерларының санын арттыру өчен шартлар тудыру һәм аларның матди-техник базасын ныгыту;

аналарның һәм балаларның сәламәтлеген ныгыту максатларында физик культура һәм спорт чараларын киң куллану өчен шартлар тудыру;

хатын-кызлар өчен, эшчәнлекләренең үзенчәлеген һәм тиешле фәнни-ысулый тәкъдимнәрне исәпкә алып, физкультура-савыктыру һәм массакүләм спорт гамәлләре оештыру;

физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлекне законнар нигезендә лицензияләүне оештыру;

физкультура-спорт оешмаларының тышкы икътисадый бәйләнешләренә ярдәм күрсәтү.

2. Иң югары спорт нәтиҗәләренә ирешү (алга таба - югары казанышлы спорт) максатларында дәүләт спорт үсешенә ярдәм күрсәтә һәм моның өчен түбәндәге юллар белән уңай шартлар тудыра:

югары класслы спортчылар әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы барлык төрдәге һәм типтагы спорт мәктәпләре, олимпия резервы училищелары санын арттыру һәм аларның матди-техник базасын ныгыту;

спортның төрле төрләре буенча Татарстан Республикасының җыелма командаларын әзерләү базаларының һәм үзәкләренең, шулай ук физкультура һәм спорт хезмәткәрләрен профессиональ әзерләүнең һәм аларның квалификацияләрен күтәрүнең шартларын яхшырту максатларында урта һөнәр, югары һөнәр белеме мәгариф учреждениеләренең уку биналарын, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмаларын яңарту һәм яңаларын төзү;

югары казанышлы спортны үстерү проблемалары буенча комплекслы фәнни тикшеренүләр өчен ассигнованиеләр бүлеп бирү;

физкультура-спорт оешмаларының югары класслы спортчылар әзерләү эшчәнлеген һәм спортчыларның бөтенроссия һәм халыкара ярышларда катнашуларын кызыксындыру;

меценатлык һәм хәйрия эшчәнлеген хуплау.

3. Дәүләт Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт пропагандасын, физкультура-спорт хәрәкәтен һәм олимпия хәрәкәтен законнар нигезендә тәэмин итә.

4. Физик культурага һәм спортка, физкультура-спорт оешмаларына, спорт корылмаларына, спорт сәнәгате предприятиеләренә дәүләт ярдәме физик культура һәм спорт үсешенең билгеләнгән тәртиптә расланган барлык дәрәҗәдәге программалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Физик культура һәм спорт үсешенең барлык дәрәҗәдәге программаларын гамәлгә ашыру чыгымнары тиешле бюджетларның акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар, спорт лотереяләре уздырудан керемнәр, шулай ук законнар нигезендә башка акчалар исәбеннән тотыла.

## II бүлек. Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт системасы

### 6 статья. Татарстан Республикасында физкультура (физкультура-спорт) хәрәкәте субъектлары

Татарстан Республикасында физкультура (физкультура-спорт) хәрәкәте субъектларына түбәндәгеләр керә:

спорт клублары, мәгариф учреждениеләрендә, милек рәвешләренә карамастан, бүтән оешмаларда һәм гражданнарның яшәү урыннарында һәвәскәр һәм профессиональ нигезләрдә эшләп килүче физик культура коллективлары;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт, мәгариф өлкәсендә тиешле махсус вәкаләтле органнары, һөнәр берлекләре һәм башка оешмалар карамагында булган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре, физик яктан әзерләү буенча балалар-яшүсмерләр клублары, балалар-яшүсмерләрнең спорт-техник мәктәпләре, олимпия резервының махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр мәктәпләре, олимпия резервы училищелары, югары спорт мастерлыгы мәктәпләре, олимпиягә әзерләү үзәкләре;

барлык төрдәге һәм типтагы физик культура һәм спорт өлкәсендә, оештыру хокукый рәвешләренә карамастан, мәгариф учреждениеләре һәм фәнни оешмалар;

республика физкультура-спорт берләшмәләре, физкультура-спорт оешмалары, спортның төрле төрләре буенча республика федерацияләре (берлекләре, ассоциацияләре), иҗтимагый-дәүләти физкультура-спорт җәмгыятьләре, оборона спорт-техник оешмалары;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы, физик культура һәм спорт

өлкәсендә дәүләт идарәсенең җирле органнары, аларга буйсынучы оешмалар.

7 статья. Физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары компетенциясе

1. Физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына түбәндәгеләр керә:

физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын кабул итү һәм үзгәртү, аларның үтәлешен тикшереп тору;

физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәтен билгеләү;

физик культура һәм спорт үсешенең республика программаларын раслау;

Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт буенча бюджеттан тыш фондын раслау;

физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасының мактаулы исемнәрен билгеләү, Татарстан Республикасы бүләкләрен, дәүләт премияләрен гамәлгә кую;

физкультура һәм спорт өлкәсендә гражданнарның хокуклары, ирекләре һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне карау.

2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында төзелгән шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә физик культураны һәм спортны үстерүнең федераль программаларын әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

физик культура һәм спорт өлкәсендә агымдагы һәм перспектив дәүләт программалары әзерләү һәм аларны гамәлгә ашыру, аларның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хисап бирү;

физик культура-спорт берләшмәләрен, шул исәптән Татарстан Республикасы исеменнән халыкара спорт гамәлләрендә катнашучы

физик культура-спорт берләшмәләрен аккредитацияләү тәртибен билгеләү;

физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең эшчәнлеген бәяләүнең бердәм критерийларын билгеләү;

физик культура һәм спорт өлкәсендәге фәнни тикшеренүләрне финанслауны тәэмин итү;

физкультура һәм спорт өлкәсендә республика әһәмиятенә ия спорт корылмаларын, спортка әзерләү үзәкләрен һәм башка оешмаларны (берләшмәләрне) финанслауны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы җыелма командаларын әзерләүне һәм аларның Татарстан Республикасы Дәүләт флагы астында уздырыла торган рәсми спорт ярышларында катнашуларын финанслауны тәэмин итү (моңа фәнни-медицина тәэминаты да керә);

физик культураны һәм спортны үстерүнең республика программасы нигезендә физик культура һәм спорт системасын фәнни-ысулый тәэмин итү, физик культура һәм спорт буенча фәнни, уку-укыту һәм популяр әдәбият бастыруны оештыру;

физик культура һәм спорт өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итүнең республика бердәм системасын булдыру;

Татарстан Республикасы спортчыларының һәм җыелма командаларының спорт гамәлләрендә катнашу тәртибен билгеләү.

8 статья. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы компетенциясе

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

физик культураны һәм спортны үстерүнең республика программаларын гамәлгә ашыру;

физик культура һәм спорт өлкәсендә законнар нигезендә лицензияләү;

Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт үсешенең йомгакларын ел саен карау һәм әлеге өлкәдә киләчәк ел гамәлләрен раслау;

гражданнарны физик тәрбияләүгә җитәкчелек итү һәм физик культураны гражданнарның хезмәт һәм ял режимына кертү, массакүләм спорт ярышларын, спартакиадаларны, физкультура-спорт фестивальләрен, физкультура-савыктыру гамәлләрен оештыру, Татарстан Республикасының җыелма командасы өчен спортның төрле төрләре буенча резервлар әзерләүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең мәгариф өлкәсендә һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органнары белән берлектә, мәгариф учреждениеләренең уку-укыту процессына укучылар өчен үтәлүе мәҗбүри булган физик әзерлекнең норматив таләпләрен кертү;

шушы өлкәдә фәнни тикшеренүләр һәм экспериментлар нигезендә халыкның төрле категорияләрен физик тәрбияләүнең дәүләт программаларына физик күнегүләрнең һәм спортның яңа төрләрен кертү;

массакүләм физик культураны, спортны, сәламәт тормыш рәвешен, физик культура һәм спорт белемнәре нигезләрен, популяр физкультура-савыктыру һәм спорт программаларын, физик күнегүләрнең комплексларын пропагандалау, шулай ук бу өлкәдә массакүләм әдәбият бастырып чыгару һәм видео-, киноматериаллар чыгару;

халыкка физкультура-савыктыру хезмәтләре күрсәтү нормативларын билгеләү;

Татарстан Республикасы исеменнән халыкара спорт гамәлләрендә катнашучы физкультура-спорт берләшмәләрен аккредитацияләү;

спортның милли төрләре буенча бердәм республика спорт классификациясен, физкультура-савыктыру һәм спорт гамәлләренең бердәм календарь планын, спортта дәрәҗәле исемнәр бирү турында нигезләмәләрне һәм физик культура һәм спорт турында башка норматив актларны әзерләү һәм раслау;

физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрне профессиональ әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү гамәлләре;

спорт корылмаларын төзүне оештыру һәм гамәлдәге спорт корылмаларын тоту, бу мәсьәләләрдә физкультура-спорт берләшмәләренә ярдәм күрсәтү;

физик культура һәм спорт үсешенең социаль нормативлары үтәлешен, шулай ук физкультура-савыктыру һәм спорт корылмаларыннан файдалану нормалары һәм кагыйдәләре үтәлешен тикшереп тору;

гражданнарның физкультура-спорт һәм туристлык билгеләнешендәге товарларга ихтыяҗын өйрәнү, спорт сәнәгасенең дәүләт предприятиеләрендә аларны җитештерүне оештыру, спорт сәнәгасенең башка предприятиеләрендә әлеге товарларны җитештерүне җайга салу, күрсәтелгән товарларның сыйфатын һәм ассортиментын тикшереп тору чараларын күрү;

физкультура-спорт оешмаларының эшчәнлеген дәүләт статистикасы белешмәләре нигезендә ел саен анализлау;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органы белән берлектә физкультура-спорт өлкәсендә өстәмә белем бирүче дәүләт учреждениеләре турында норматив документларны әзерләү;

физкультура һәм спорт өлкәсендә өстәмә белем бирүче дәүләт учреждениеләренең эшчәнлеген Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органы белән берлектә җайга салу.

Милек рәвешләренә һәм финанслау чыганакларына карамастан, физик культура һәм спорт өлкәсе учреждениеләре өчен Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органының үз компетенциясенә кергән мәсьәләләре буенча карарларын үтәү мәҗбүри.

<u>9 статья.</u> Физик культура һәм спорт өлкәсендә районнарның, шәһәрләрнең һәм шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре компетенциясе

Физик культура һәм спорт өлкәсендә районнарның, шәһәрләрнең һәм шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

физкультура-спорт үсешенең җирле программаларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы жыелма командалары әгъзаларының әзерлеген һәм аларның ярышларда катнашуларын тәэмин итү;

физкультура-савыктыру һәм массакүләм спорт гамәлләренең календарь планнарын әзерләү һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән ярышларны һәм укыту-күнекмә җыеннарын оештыру;

дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә җирле органнарын булдыру һәм аларның эшчәнлеген һәм үзара хезмәттәшлеген җайга салу;

физик культураны һәм спортны төрле яшьтәге халык төркемнәренең уку, хезмәт һәм ял итү режимнарына физик яктан әзерлекнең расланган нормативлары нигезендә кертү;

физкультура-спортның коммуналь учреждениеләрен, спорт мәктәпләрен, барлык төрдәге үзәкләрен һәм клубларын булдыру һәм финанслау, Татарстан Республикасы җыелма командалары өчен югары квалификацияле спортчыларның резервларын әзерләүне тәэмин итү.

**10 статья. Физик культура һәм спорт өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясе**

Җирле үзидарә органнары җирле үзидарә турында Татарстан Республикасы законнарында билгеләнә торган үз компетенцияләре чикләрендә физик культура һәм спорт үсешен гамәлгә ашыралар.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә җирле үзидарә органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

гражданнарның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә хокукларын гамәлгә ашыру;

җирле үзидарә территориясендә физик культура һәм спорт үсеше программаларын кабул итү;

җирле үзидарә территорияләрендә физик культура һәм спорт учреждениеләрен булдыру һәм аларны финанслау;

җирле үзидарә бюджетларының физик культураны һәм спортны финанслау өлешен булдыру;

мәгариф учреждениеләрендә җирле үзидарә бюджетлары исәбеннән физик культура һәм спорт буенча өстәмә уку дәресләре һәм укудан тыш дәресләр кертү.

11 статья. Татарстан Республикасында олимпия хәрәкәте

Дәүләт Татарстан Республикасында олимпия хәрәкәтен таный һәм хуплый.

Татарстан Республикасында олимпия хәрәкәте Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы белән Россия Федерациясе Олимпия комитеты арасында төзелгән шартнамәдә билгеләнгән компетенция чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы тарафыннан җайга салына.

12 статья. Физкультура-спорт берләшмәләре һәм физкультура-спорт оешмалары

1. Татарстан Республикасында физкультура-спорт берләшмәләре булдырыла һәм эшләп килә, шул исәптән дәүләт катнашында да. Аларга һөнәр берлекләренең физкультура-спорт җәмгыятьләре, дәүләт хакимияте органнарының физкультура-спорт җәмгыятьләре, спортның төрле төрләре буенча федерацияләр (берлекләр һәм ассоциацияләр) (шул исәптән профессиональ спортта аларның структур бүлекчәләре) керә.

2. Физкультура-спорт берләшмәләрен (федерацияләрен, берлекләрен, ассоциацияләрен) төзү, теркәү, үзгәртеп кору һәм бетерү тәртибе законнар белән билгеләнә.

Спорт төрләренең катлаулылыгы һәм башка үзенчәлекләре буенча Татарстан Республикасының 50 процентыннан артмаган территориясендә генә эшләү мөмкинлеге булган берләшмәләр республика берләшмәләре (федерацияләре, берлекләре, ассоциацияләре) дип таныла.

Мондый берләшмәләрнең исемлеген Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы билгели.

3. Төп максатлары, функцияләре, структурасы, әгъзалык, идарә итү органнарын сайлау, хуҗалык эшчәнлеге, спортчыларны һәм физкультура һәм спорт хезмәткәрләрен финанслау, социаль яклау, үз

символикасын гамәлгә кую мәсьәләләре физкультура-спорт берләшмәләре уставларында карала.

Республика физкультура-спорт берләшмәләренең житәкче органнарына Татарстан Республикасында яшәүче гражданнар сайлана.

Татарстан Республикасының физкультура-спорт берләшмәләре халыкара спорт берләшмәләренә (федерацияләренә, берлекләренә, ассоциацияләренә) керергә, халыкара берләшмәләрнең статусына туры килерлек хокукларга ия булырга һәм вазыйфалар үтәргә мөмкин, мондый хокуклар һәм вазыйфалар халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына каршы килмәскә тиеш.

4. Физкультура-савыктыру һәм спорт гамәлләренең бердәм календарь планы нигезендә каралган Татарстан Республикасы чемпионатларын, Татарстан Республикасы беренчелегенә, кубокларына ярышларны һәм Татарстан Республикасының башка рәсми спорт ярышларын, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларын, бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында катнашуга әзерләнү гамәлләрен, спортның төрле төрләре буенча Татарстан Республикасы җыелма командаларының аларда катнашу гамәлләрен спортның төрле төрләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы аккредитацияләгән республика федерацияләре (берлекләре, ассоциацияләре) уздырырга хокуклы.

Аккредитацияләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасында теләсә нинди оештыру-хокукый рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге физкультура-спорт оешмалары - физкультура-савыктыру, спорт оешмалары, спорт-техник клублар һәм физик культура коллективлары законнарда каралган тәртиптә төзелә.

Спорт клублары һәм физик культура коллективлары үз уставлары нигезендә гражданнар арасында, шул исәптән балалар арасында һәм мәгариф учреждениеләрендә укучылар, ветераннар, инвалидлар арасында, физкультура-савыктыру эшләре оештыралар.

6. Физик культураны һәм спортны үстерүнең республика программаларындагы аерым бүлекләрне үтәүче Татарстан

Республикасының физкультура-спорт берләшмәләре шул максатлар өчен Татарстан Республикасының республика бюджетында каралган акчалар исәбеннән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә финанс һәм бүтән төрле дәүләт ярдәме алырга хокуклы.

Татарстан Республикасының физкультура-спорт берләшмәләрен, шул исәптән спорт клубларын һәм физик культура коллективларын финанслау оешмаларның һәм спонсорларның (аларның уставлары нигезендә) финанс ярдәме, гражданнарның иганәләре нигезендә, шулай ук спорт лотереяләрен, ярышларын уздырудан, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырудан керемнәр исәбеннән һәм законда тыелмаган башка чыганаклардан финансланырга мөмкин.

## 13 статья. Спорт юнәлешендәге өстәмә белем бирү учреждениеләре

Балаларны һәм яшьләрне даими рәвештә физкультура-спорт дәресләренә җәлеп итүне, аларны физик камилләштерү өчен шартлар тудыруны спорт юнәлешендәге өстәмә белем бирү учреждениеләре гамәлгә ашыралар.

Өстәмә белем бирү учреждениеләренең эшчәнлеген оештыру һәм финанслау тәртибе гамәлгә куючы тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.

## 14 статья. Спортның төрле төрләре буенча Татарстан Республикасының җыелма командалары

1.Татарстан Республикасының җыелма командалары - спортның төрле төрләре буенча федерацияләрнең состав өлешен тәшкил итүче спортчылар, тренерлар, галимнәр, физкультура-спорт оешмаларының һәм спорт буенча медицина оешмаларының башка хезмәткәрләре коллективлары бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларына әзерләнү һәм аларда Татарстан Республикасының Дәүләт флагы астында катнашу максатларында төзелә.

2. Спортның төрле төрләре буенча Татарстан Республикасының җыелма командалары, шәһәрләрдәге, районнардагы, шәһәр районнарындагы физкультура-спорт оешмаларының тәкъдимнәрен исәпкә алып, спортның төрле төрләре буенча тиешле республика федерацияләре тарафыннан конкурс нигезендә оештырыла. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы һәм спортның төрле төрләре буенча республика федерацияләре тарафыннан билгеләнгән спорт принципларын, алдан билгеләнгән һәм игълан ителгән махсус нормативларны үтәгән спортчылар Татарстан Республикасының җыелма командалары составларына кертеләләр. Татарстан Республикасы җыелма командаларының билгеләнгән нормативларны үтәмәүче, үз вазыйфаларын даими рәвештә бозучы әгъзалары Татарстан Республикасының җыелма командаларыннан чыгарылырга мөмкин.

Татарстан Республикасының җыелма командалары составлары спортның төрле төрләре буенча республика федерацияләре тәкъдимнәре буенча Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы тарафыннан ел саен раслана.

Татарстан Республикасының җыелма командаларын финанслау, шул исәптән аларны бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларына әзерләү һәм аларда катнашу өчен финанслау тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән, законда тыелмаган бүтән чыганаклардан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

**15 статья.** Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсе органнары белән физкультура-спорт оешмаларының үзара хезмәттәшлеге

Физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары:

физкультура-спорт берләшмәләре белән физик культураны һәм спортны үстерүнең барлык мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек итәләр, физкультура-спорт һәм олимпия хәрәкәтенең актуаль мәсьәләләре буенча аларның эшчәнлеген җайга салалар, кирәк

булганда бергәләп ярышлар, спартакиадалар, физкультура-спорт фестивальләре уздыралар, кадрлар әзерләүне, физкультураны һәм спортны пропагандалауны, спорт корылмаларын төзүне, ремонтлауны һәм тотуны һәм башка гамәлләрне оештыралар;

физкультура-спорт берләшмәләренә ярдәм күрсәтәләр, аларның устав бурычларын үтәүләренә ярдәм итәләр, физик культура һәм спорт үсешенең төп мәсьәләләре буенча мәгълүмат тынлыйлар, тиешле карарлар кабул итәләр һәм аларның үтәлешен тикшереп торалар. Уртак эшчәнлек шартнамәчел мөнәсәбәтләр нигезендә гамәлгә ашырыла;

физкультура-спорт берләшмәләре тарафыннан бирелүче мәгълүматларны законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган рәвешләрдә җыюны гамәлгә ашыралар, алар буенча тиешле бәяләмәләр һәм рекомендацияләр бирәләр.

16 статья. Физик культура һәм спорт үсешен фәнни-ысулый һәм техник яктан тәэмин итү

1. Физик культура һәм спорт өлкәсендә фундаменталь, эзләнү, тәҗрибә-конструкторлык, технологик, гамәли һәм башка фәнни-тикшеренү эшләрен оештыруны һәм уздыруны билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм үз эшчәнлекләрен дәүләт заказлары һәм бүтән заказлар нигезендә тормышка ашыручы дәүләт фәнни үзәкләре, фәнни-тикшеренү институтлары, лабораторияләр, физик культура һәм спорт өлкәсендә мәгариф учреждениеләр законнар нигезендә башкаралар.

Мондый үзәкләрне, институтларны, мәгариф учреждениеләрен финанслау тиешле бюджет ассигнованиеләре исәбеннән, физкультура-спорт оешмаларының заказлар үтәүдән кергән керемнәре, фәнни бүлекчәләрнең эшкуарлык эшчәнлегеннән кергән керемнәре һәм законда тыелмаган бүтән чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә фәнни-тикшеренү оешмалары һәм аларның бүлекчәләре физик культура чаралары белән халыкның сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итүче конкрет программаларны әзерлиләр һәм аларны гамәлгә кертәләр (мондый программаларны гамәлгә ашырганда телевидение һәм радиотапшыруларның федераль һәм төбәк хезмәтләре катнашалар),

спорт резервларын һәм Татарстан Республикасының җыелма командаларын бөтенроссия һәм халыкара ярышларында катнашу өчен әзерләүне фәнни яктан тәэмин итүне камилләштерәләр.

3. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы, дәүләт идарәсенең кызыксынучы бүтән органнары һәм физкультура-спорт берләшмәләре физик культура һәм спорт өлкәсендәге фәнни оешмаларга һәм аларның бүлекчәләренә актуаль фәнни-тикшеренү эшләренә дәүләт заказларын һәм бүтән заказларны оештыруда ярдәм күрсәтәләр, мондый фәнни оешмаларга һәм аларның бүлекчәләренә өстәмә финанслау чыганакларын җәлеп итүдә ярдәм итәләр, фәнни-тикшеренү эшләре йомгакларын анализлыйлар.

## III бүлек. Физкультура-савыктыру эше һәм спортта югары казанышларга ирешү

### 17 статья. Дәүләт хакимияте органнарының, мәгариф учреждениеләренең һәм башка оешмаларның гражданнарга физик тәрбия бирүдә катнашулары

1. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, мәгариф учреждениеләре, милек рәвешләренә карамастан, оешмалар, мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә һәм белем алучыларга, хәрби хезмәткә чакыру яшенә җитмәгән һәм хәрби хезмәткә чакыру яшендәге гражданнарга, инвалидларга, пенсионерларга, башка гражданнарга, дәүләт социаль сәясәтенең мөһим юнәлеше буларак, физик тәрбия бирүне карыйлар, физик культура һәм спорт үсешенең физкультура-спорт, һөнәр берлекләре, яшьләр оешмалары һәм башка оешмалар катнашында республика программаларын гамәлгә ашыралар һәм шулар нигезендә районнарның, шәһәрләрнең һәм шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә үз программаларын эшлиләр, аларда түбәндәгеләр күздә тотыла:

мәгариф учреждениеләрендә, балаларны савыктыру, яшьләр һәм спорт лагерьларында физик әзерлекнең мәҗбүри норматив таләпләре нигезендә физик тәрбияләү сыйфатын күтәрү;

гражданнарны даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, һәр хезмәт коллективында хезмәтне һәм ялны фәнни оештыру системасына эш урыны гимнастикасын, хезмәттән соң реабилитацияләүне мәҗбүри рәвештә гамәлгә кертү;

чирләрне профилактикалауда һәм дәвалауда физик күнегүләрне куллануның нәтиҗәлелеге турындагы белемнәрне пропагандалау һәм физик культура, спорт белән шөгыльләнүче гражданнарны табиб тарафыннан тикшереп торуны камилләштерү;

гамәлдәге спорт корылмаларын киңәйтү һәм реконструкцияләү, физкультура-савыктыру эшләре уздыру һәм спорт резервлары әзерләү өчен яңа спорт корылмалары төзү.

2. Дәүләт идарәсенең республика һәм җирле органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, һөнәр берлекләре социаль проблемалар һәм хезмәтне саклау килешүләренә физик культураны һәм спортны үстерү мәсьәләләрен кертәләр, мондый килешүләрнең, физик культура һәм спорт үсеше буенча үз программаларының үтәлешен тикшереп торуны оештыралар.

18 статья. Мәгариф учреждениеләрендә физик тәрбия

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны физик тәрбияләүнең максаты баланы һәрьяклап физик һәм рухи үстерүдән гыйбарәт. Бу яшьтәге балаларны физик тәрбияләү - ата-аналарның яисә аларны алмаштыручы затларның бурычы.

Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә физик тәрбия мәҗбүри була һәм ул фәнни расланган программалар һәм санитария-гигиена таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларны физик тәрбияләү уку-укыту планнары, дәүләтнең физик тәрбия буенча комплекслы программалары һәм санитария-гигиена таләпләре нигезендә уку вакытында һәм озайтылган көн режимында укудан тыш вакытта һәм мөстәкыйль режимда көн саен башкарыла.

Укудан тыш вакытта физик күнегүләр һәм шөгыльләнү өчен районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре тарафыннан клублар һәм мәктәптән тыш физкультура-савыктыру учреждениеләре төзелә.

3. Башлангыч һөнәр, урта һөнәр һәм югары һөнәр белеме учреждениеләрендә белем алучыларны физик тәрбияләү барлык уку чорында мәҗбүри була һәм ул дәресләр рәвешендә һәм физик культурадан һәм спорттан файдалануга юнәлдерелгән академиячел булмаган рәвешләрдә уку-укыту программалары нигезендә башкарыла.

4. Сәламәтлекләре какшаган укучылар махсус медицина төркемнәрендә һәм физик культура белән дәвалау төркемнәрендә шөгыльләнәләр.

5. Дәүләт идарәсенең мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәсендәге республика һәм жирле органнары, шулай ук үз уставлары нигезендә мәгариф учреждениеләре, аларның житәкчеләре:

укыту барышында һәр көнне уку дәресләре һәм укудан тыш дәресләрне югары дәрәжәдә бирүне тәэмин итәләр, һәр укучы йөзәргә өйрәнсен, билгеләнгән спорт нормативларын үтәсен, гигиена нигезләрен өйрәнсен һәм үз организмын яхшы халәттә тотарга өйрәнсен өчен шартлар тудыралар;

«Физкультура һәм сәламәтлек» бөтенроссия комплексы нормативлары нигезендә барлык мәгариф учреждениеләрендә укыту цикллары буенча күп мәртәбә ярышлар уздыралар, район, шәһәр, республика спорт ярышларында укучыларның катнашуын тәэмин итәләр.

Барлык гомуми белем бирү учреждениеләрендә, шулай ук башлангыч һөнәр, урта һөнәр һәм югары һөнәр белеме учреждениеләрендә уку елы йомгаклары буенча һәр укучыга аның физик әзерлегенә билге куела, чыгарылыш сыйныфларда (курсларда) контроль тикшерүләр уздырыла.

6. Физик культураны һәм спортны үстерүнең барлык дәрәжәдәге программалары нигезендә мәгариф учреждениеләрендә спорт залларын, йөзү бассейннарын һәм спорт шәһәрчекләрен реконструкцияләү һәм төзү, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрен, балаларны-яшүсмерләрне физик әзерләү клубларын һәм табиб-физкультура диспансерларын булдыру карала.

19 статья. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең балалар һәм яшьләр эшләре буенча махсус вәкаләтле органының һәм дәүләт идарәсенең балалар һәм яшьләр эшләр буенча җирле органнарынын физкультура-савыктыру эшләрен, балалар һәм яшьләр арасында спорт эшләрен оештыруда катнашулары

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең балалар һәм яшьләр эшләре буенча махсус вәкаләтле органы һәм дәүләт идарәсенең балалар һәм яшьләр эшләре буенча җирле органнары:

балалар һәм яшьләр арасында физкультура-савыктыру эшләрен оештыруда катнашалар, сәламәт тормыш алып баруны формалаштыру максатларында аларны даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итүдә ярдәм күрсәтәләр, балалар һәм яшьләр кылган хокук бозуларны профилактикалау гамәлләре башкаралар, физкультура-спорт оешмалары белән берлектә массакүләм спорт ярышлары һәм спартакиадалар уздыралар;

яшьләр, балалар оешмалары һәм башка оешмалар катнашында физкультура-савыктыру һәм спорт клублары, шул исәптән оборона-спорт клублары булдыралар, балаларның һәм яшьләрнең физик әзерлеген һәм аларның «Физкультура һәм сәламәтлек» бөтенроссия комплексы нормативларын үтәүләрен оештыралар;

массакүләм физкультура һәм спорт гамәлләрен уздыру өчен законнар нигезендә тиешле акчаларны бүлеп бирәләр.

20 статья. Оешмаларда, халыкның яшәү һәм ял итү урыннарында физик культура

1. Милек рәвешләренә карамастан, оешмаларның җитәкчеләре һөнәр берлекләре белән берлектә, ә алар булмаганда - хезмәткәрләрнең законнар нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре белән берлектә, күмәк шартнамәләр төзү шарты белән түбәндәгеләрне үтәргә тиешләр:

хезмәткәрләргә физик культура белән шөгыльләнү хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруны тәэмин итәргә, моңа эш көне режимындагы реабилитацион һәм һөнәри-гамәли шөгыльләр,

хезмәттән соң тернәкләнү, профилактик шөгыльләр, массакүләм спорт эше, спорт-савыктыру туризмы да керә;

хезмәткәргә һәм аларның гаилә әгъзаларына физкультура һәм спорт белән индивидуаль һәм күмәк шөгыльләнүне оештыру өчен матди база тудыру, алардан файдалану, финанслау, белгечләр белән тәэмин итү шартларын билгеләргә.

2. Яшәү урынарында, күпләп ял итү урыннарында халыкка физик культура белән шөгыльләнү өчен мөстәкыйль спорт, физкультура-савыктыру, туристлык,спорт-патриот клублары, төркемнәре һәм командалары төзелә.

Районнарның, шәһәрләрнең һәм шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре һәм җирле үзидарә органнары халыкка тору урыннарында һәм күпләп ял итү урыннарында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруны тәэмин итәләр, ул физкультура һәм спортны үстерү программаларын финанслау буенча дәүләт нормативлары нигезендә җирле бюджетлар, җирле үзидарә бюджетлары исәбеннән башкарыла.

3. Шифаханә-курорт учреждениеләре, ял йортлары һәм туристлык базалары администрацияләре ял итүчеләрнең сәламәтлекләрен ныгыту, профилактика һәм авыруларны дәвалау максатында дәвалау һәм ял итү барышында физик культураның төрле компонентларыннан файдалану өчен шартлар тудырырга тиеш.

21 статья. Инвалидларның физик культурасы һәм спорты

Инвалидларның физик культурасын һәм спортын үстерү аларның хәрәкәтләнү активлыгын арттыруга юнәлдерелгән һәм инвалидларны һәрьяклап реабилитацияләү һәм социаль адаптацияләүдә һичшиксез һәм билгеләүче шарт булып тора.

Инвалидларны (физик үсешләрендә төрле тайпылышлар булган балаларны да кертеп) өзлексез реабилитацияләү системасында физик культура һәм спорт дәресләре оештыру, социаль хезмәткәрләрне, физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләрен әзерләү, ысулый һәм медицина ягыннан тәэмин итү, табиб тикшереп торуы мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль тәэминат учреждениеләре, шулай ук

физкультура һәм спорт өлкәсендәге оешмалар тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы, физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсенең җирле органнары, районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре, җирле үзидарә органнары, физкультура-спорт берләшмәләре, инвалидларның физкультура-спорт берләшмәләре белән берлектә инвалидлар белән физкультура-савыктыру һәм спорт гамәлләрен уздыруда, инвалид спортчылар әзерләүдә һәм аларны бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларына җибәрүне тәэмин итүдә катнашалар.

22 статья. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең сәламәтлек саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органының һәм сәламәтлек саклау учреждениеләренең физик культура һәм спортны үстерүдә катнашулары

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең сәламәтлек саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органы һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә:

физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларның табиб тарафыннан тикшереп торылуын гамәлгә ашыралар;

халыкның физик үсеше дәрәҗәсен билгелиләр;

яшәү урыннарында индивидуаль принципларда халык белән физкультура-савыктыру эшен тәэмин итүче физик культура чаралары белән тиешле савыктыру һәм реабилитацияләү үзәкләре һәм пунктлары, диагностика-консультация пунктлары, кабинетлар һәм диспансерлар булдыралар;

чирләрне профилактикалау һәм дәвалау чарасы буларак физик культурадан файдаланалар;

физик культураның төп компонентларыннан (физик күнегүләр, чыныктыру, сулыш юллары гимнастикасы, аутотренинг, массаж һәм үз-үзенә массаж) һәм кешенең сәламәтлеген ныгытуга йогынты ясардай башка чаралардан нәтиҗәле файдалану мәсьәләләре буенча сәламәтлек саклау белгечләрен әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрүне оештыралар һәм гамәлгә ашыралар.

**23 статья.** **Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнгәндә гражданнарның сәламәтлеген саклау**

Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү аркасында сәламәтлегенә зыян китерелгән гражданнарга, шул исәптән спортчыларга, тренерларга һәм спорт төрләре буенча судьяларга законнар нигезендә, оешкан рәвештә медицина, социаль һәм профессиональ реабилитацияләү күрсәтелә.

## IV бүлек. Физик культураны һәм спортны пропагандалау

**24 статья.** Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнарының, физкультура-спорт берләшмәләренең һәм массакүләм мәгълүмат чараларының физик культураны һәм спортны пропагандалауда катнашулары

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә, сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органнары, физкультура-спорт берләшмәләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, халыкның төрле төркеменең яшь, һөнәри һәм социаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, физик культураны һәм спортны пропагандалау рәвешләрен һәм ысулларын билгелиләр, физик тәрбиянең социаль әһәмиятен ачуны тәэмин итәләр, аның халыкны савыктыруда тәмәке тарту, алкоголь, наркотиклар куллану, балалар җинаятьчелеге кебек тискәре күренешләргә каршы көрәштә ролен билгелиләр.

Массакүләм мәгълүмат чаралары, шул исәптән телевизион компания һәм радиокомпания, газеталар, журналлар һәм башка вакытлы басмалар, аларның редакцияләре, гамәлгә куючылары һәм оештыручылары даими тапшырулар уздыруны, махсус рубрикалар бирүне оештыралар, белем бирү - агарту характерында системалы материаллар бирүне һәм бастырып чыгаруны оештыралар, гражданнарда физик күнегүләр белән шөгыльләнүгә ихтыяҗ тудыралар, гражданнарның гигиена, медицина, туклану режимы, хезмәт һәм ял оештыру өлкәсендә белем белән кызыксынуын

арттыралар, физик күнегүләр комплексларын, шул исәптән өй шартларында мөстәкыйль шөгыльләнү өчен дә, популярлаштыралар, дәүләтнең һәм җиң җәмәгатьчелекнең әлеге проблемаларга игътибарын җәлеп итәләр, хезмәт коллективларының, гражданнарның тормыш эшчәнлегенә физик культураны уңышлы рәвештә гамәлгә кертүче физкультура-спорт оешмаларының тәҗрибәләрен яктырталар, Татарстан Республикасында олимпия һәм спортның башка төрләренең үсеше турында мәгълүмат бирәләр.

Спортта кырыслык һәм көч куллануны, кешелек абруен төшерүне, норматив актлар белән тыелган һәм кешенең сәламәтлегенә зыян китерә торган стимуляторлар куллануны пропагандалау тыела; теле- һәм радиотапшыру каналлары буенча физкультура-савыктыру һәм спорт программаларын трансляцияләгән вакытта алкогольле эчемлекләрне һәм тәмәке әйберләрен рекламалау тыела.

## 25 статья. Теле- һәм радиотапшырулар каналлары буенча физик культура һәм спортны пропагандалау

1. Телевидение һәм радиотапшырулар буенча дәүләт хезмәтләре законнар нигезендә спорт программаларын трансляцияләүне күздә тоталар, башка милек рәвешләрендәге телевидение компанияләре һәм радио компанияләре спорт программаларын трансляцияләүгә ярдәм итәләр, шул исәптән:

савыктыруга юнәлдерелгән көндәлек тапшыруларны (иртәнге һәм эш урынындагы гимнастиканы) оештыралар, тамашачыларда физик культура һәм спорт белән мөстәкыйль шөгыльләнергә кызыксыну уята торган, әлеге өлкәдә тиешле белем бирә торган, гражданнарда актив сәламәт тормышка ихтыяҗ формалаштыра торган теле-һәм радио программаларның, кинофильмнарның, электрон һәм компьютер уеннарының, башка материалларның югары дәрәҗәсен тәэмин итәләр;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы, физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсенең җирле органнары, спортның төрле төрләре буенча федерацияләр, физкультура-спорт берләшмәләре советлары белән тыгыз хезмәттәшлек урнаштырып, спортның аеруча популяр төрләре буенча спорт ярышлары турында теле- һәм радио

тапшырулар каналлары буенча даими репортажлар оештыралар, башка төрле спорт программалары әзерлиләр, төрле телевидение һәм радио компанияләренең спорт редакцияләре эшчәнлеген җайга салалар. Бу очракта гражданнарның ял итүгә булган конституциячел хокукларын тәэмин итү, тамашачыларны күбрәк җәлеп итү, бюджет акчаларын экономияләү максатларында, күрсәтелгән оешмалар белән берлектә, аеруча дәрәҗәле ярышларны халык барыннан да элек күп карый һәм тыңлый торган теле- һәм радио каналларда яктырту тәртибен билгелиләр.

2. Телевидение һәм радио тапшырулар буенча дәүләт хезмәтләрен физкультура-савыктыру һәм спорт юнәлешендәге программаларны Татарстан Республикасының Республика бюджеты, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән һәм законда тыелмаган бүтән чыганаклардан өстенлекле тәртиптә финанслауны тәэмин итәләр, башка төрле милек рәвешләрендәге телевидение һәм радио компанияләре, спорт ярышларын һәм башка спорт гамәлләрен теле- һәм радио тапшырулар каналлары буенча трансляцияләүнен, спорт ярышларын һәм башка спорт гамәлләрен фотога һәм кинога төшерүнен һәм әлеге язмаларның тавышын яздыруның, бары тик спорт ярышларын һәм башка спорт гамәлләрен оештыручылар тарафыннан рөхсәтләр бирелгән йә спорт ярышларын оештыручылардан хокуклар алу турында язма рәвештә килешүләр булганда гына гамәлгә ашырылганын исәпкә алып, үз акчалары исәбеннән финанслыйлар. Спорт ярышлары яисә башка спорт гамәлләре уздырганда товарларны, әйберләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне рекламалау шулай ук спорт ярышларын яисә башка спорт гамәлләрен оештыручыларның рөхсәте булганда гына башкарыла.

## V бүлек. Спортчыларның, физкультура-спорт оешмаларының, физкультураны иҗтимагый оештыручыларның хокуклары һәм бурычлары, аларны социаль яклау

### 26 статья. Һәвәскәр спортчының (физкультурачының) хокуклары һәм бурычлары

Спорт ярышларында физкультура-спорт оешмасы исеменнән катнашучы һәвәскәр спортчы (физкультурачы) законнар нигезендә түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт физкультура-савыктыру һәм спорт корылмаларыннан, медицина хезмәте күрсәтелүдән, спорт җиһазлары һәм киемнәре белән тәэмин ителүдән, шулай ук җыелма командалар составында спорт ярышлары вакытында торак һәм азык-төлек белән тәэмин ителүдән түләүсез файдалануга;

Татарстан Республикасының җыелма командалары составында күнекмә җыеннарында һәм спорт ярышларында катнашканда төп эш, хезмәт, уку урыны буенча акчалата компенсация алырга;

законнарда билгеләнгән бүтән ташламалардан һәм гарантияләрдән файдаланырга.

Һәвәскәр спортчы (физкультурачы) түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

урыннарда, республика, бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында физкультура-спорт оешмаларының абруен якларга;

үзләренең ихтыярый-әхлакый сыйфатлары турында кайгыртырга, югары гражданлык хисен күрсәтергә, гигиена нигезләрен өйрәнергә, физик культура һәм спорт турында, олимпия һәм халыкара спорт хәрәкәте турында белергә;

физик культураны һәм спортны популярлаштыруда актив катнашырга;

спортта тыелган медицина препаратлары кулланмаска һәм спортта тыелган процедуралардан файдаланмаска.

### 27 статья. Профессиональ спорт

Татарстан Республикасы гражданнары профессиональ спорт белән, спортчы яисә спорт төре буенча судья буларак, Татарстан

Республикасы, Россия Федерациясе территориясендә, шулай ук башка илләрдә дә шөгыльләнергә хокуклы.

Профессиональ спорт өлкәсендәге оешмалар эшчәнлеген төзү тәртибе һәм шартлары законнар белән җайга салына.

Спортчы һәм спорт төре судьясы һөнәренә белгечлек таләпләре профессиональ спорт эшчәнлеген җайга салучы бөтенроссия һәм халыкара спорт оешмалары актлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

28 статья. Спорт эшчәнлеге турында контракт

Спорт эшчәнлеге турында контракт хезмәт турындагы законнар нигезендә төзелә, ул спортчы, профессиональ спортчы (тренер, белгеч) белән физкультура-спорт оешмасы, шул исәптән профессиональ спорт клубы һәм командасы җитәкче арасында язма рәвештә төзелгән килешүдән гыйбарәт һәм ул, әгәр спортчы Татарстан Республикасының җыелма командасы составына керсә, спортның тиешле төре буенча республика федерациясендә исәпкә алынырга тиеш.

Спорт эшчәнлеге турындагы контрактта спортчының бурычлары, аның социаль һәм медицина иминләштерүенә хокуклары, мондый контрактны төзү һәм өзү шартлары булырга тиеш. Спорт эшчәнлеге турындагы контрактта бүтән шартлар һәм йөкләмәләр дә булырга тиеш.

Физкультура-спорт оешмасы спортчыга спорт ярышларына әзерләнү һәм аларда катнашу өчен шартлар тудыра, хезмәт хакын вакытында түли, спорт эшчәнлеге турындагы контрактта каралган, законнарга каршы килми торган бүтән йөкләмәләрне үти.

29 статья. Спортчыларның бүтән физкультура-спорт оешмаларына күчүе

Спортчы спорт эшчәнлеге турындагы конкракт вакыты беткәннән һәм шул контракттагы йөкләмәләр үтәлгәннән соң бер физкультура-спорт оешмасыннан (спорт клубыннан) икенче физкультура-спорт

оешмасына (спорт клубына) яисә чит илнең физкультура-спорт оешмасына (чит ил спорт клубына) күчәргә хокуклы.

Әгәр спортчы бер физкультура-спорт оешмасыннан (спорт клубыннан) икенче физкультура-спорт оешмасына (спорт клубына) спорт эшчәнлеге турындагы контракт вакыты беткәнче яисә шул контрактта каралган йөкләмәләр үтәлгәнче күчсә (әгәр мондый шартлар спорт эшчәнлеге турындагы спорт контрактында күрсәтелгән булса), спортчының мондый күчүе бары тик физкультура-спорт оешмаларының (спорт клубларының) үзара килешүе буенча гына мөмкин.

Спортчыларның күчүе Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы, дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендәге жирле органнары һәм спортның тиешле төрләре буенча республика федерацияләре белән килештерелгән тәртиптә һәм вакытта гамәлгә ашырыла.

30 статья. Физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре

1. Физкультура-савыктыру һәм спорт-педагогик эш белән шөгыльләнүче һәм законнарда билгеләнгән спорт һәм профессиональ квалификацияләргә ия затлар физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре булып санала.

2. Белемнәреннән, эш стажларыннан, профессиональ әзерлек дәрәжәләреннән чыгып, физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә квалификация категорияләре билгеләнә, аларны бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының норматив хокукый актлары белән жайга салына.

3. Физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре үз эшчәнлекләрендә:

гражданнарны, яшьләренә карамастан, физик культура һәм спортка жәлеп итәләр, физкультура-савыктыру һәм спорт төркемнәре, спорт командалары һәм секцияләре санын арттыруга ярдәм итәләр, физкультура-савыктыру һәм спорт-педагогика буенча конкрет эш оештыралар, хезмәт режимын эш урынындагы гимнастиканы гамәлгә ашыру инициаторлары булып торалар;

югары классны спортчылар әзерләүне тәэмин итәләр, физик культура белән шөгыльләнүче гражданнарда, спортчыларда әхлакый граждан позициясе, милләтпәрвәрлек, хезмәт итә белү, спорт ярышлары дисциплинасын һәм кагыйдәләрен саклау кебек сыйфатлар барлыкка китерәләр;

үзләренең профессиональ квалификацияләрен даими күтәрәләр, спортчылар белән тәрбияви эшне югары дәрәҗәдә алып баралар, физик культура һәм спорт, сәламәт яшәү рәвешен актив пропагандалаучылар булып торалар.

4. Физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре физик культура һәм спорт өлкәсендә озак еллар һәм уңышлы эшчәнлекләре өчен бүләк-билгеләр белән бүләкләнү һәм мактаулы исемнәргә лаек булу хокукына ия.

Физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре махсус профессиональ физкультура-спорт эшчәнлегендәге югары казанышлары өчен дәүләт бүләкләренә һәм башка төрле бүләкләргә тәкъдим ителергә мөмкин.

Физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре билгеләр белән бүләкләнергә мөмкин һәм аларга мактаулы исемнәр бирелергә мөмкин, алар исә законнар нигезендә гамәлгә куела.

31 статья. Физик культура һәм спорт өлкәсендә профессиональ педагогик эшчәнлек һәм дәвалау физкультурасы өлкәсендә профессиональ эшчәнлек

Физик культура һәм спорт өлкәсендә профессиональ педагогик эшчәнлек белән мәгариф учреждениесе биргән "физик культура һәм спорт" дигән белгечлек буенча һөнәри белем турында билгеләнгән үрнәктәге документы яки физик культура һәм спорт өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы яисә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы, физик культура һәм спорт өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән рөхсәткә ия булган затлар шөгыльләнә.

Дәвалау физкультурасы өлкәсендә профессиональ эшчәнлек белән "физик культура һәм спорт" белгечлеге буенча һөнәри белемгә яисә медицина белеменә ия булган затлар шөгыльләнә.

32 статья. Физкультура һәм спорт өлкәсендә белгечләр әзерләү

Физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрне әзерләү мәгариф турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт урта һөнәри һәм югары һөнәри мәгариф учреждениеләрендә физик культура һәм спорт өлкәсендә матди-техник базаны ныгытуга ярдәм итә, ул үз эченә физкультура-савыктыру, уку-укыту максатлары өчен спорт һәм спорт-техник корылмалар комплексына бер типтагы җиһазлар тупланмасын, физик культура һәм спорт өлкәсендә төрле юнәлештәге белгечләр әзерләү өчен махсуслаштырылган спорт корылмаларын, шулай ук мәгариф учреждениеләрендә укучыларны һәм спорт дисциплиналарын укытучыларны физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсенең тиешле органы тарафыннан расланган нормативлар нигезендә спорт формасы һәм аяк киемнәре белән түләүсез тәэмин итүне ала.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә урта һөнәри һәм югары һөнәри мәгариф учреждениеләрен финанслау, шул исәптән матди-техник базаны ныгыту һәм үстерү чыгымнары Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары, җирле бюджетлар акчалары һәм закон белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

33 статья. Физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең, шулай ук физкультура һәм спорт өлкәсендә дәүләт фәнни оешмалары һәм дәүләт мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органнары хезмәткәрләренең, физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләт фәнни оешмалары, дәүләт мәгариф учреждениеләре һәм оешмалары

хезмәткәрләренең квалификациясен кимендә биш елга бер тапкыр күтәрү өчен шартлар тудыра, әлеге максатларга Татарстан Республикасының республика бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән акчалар бүлеп бирә.

Физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләт фәнни оешмалары һәм дәүләт мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү физик һәм (яисә) юридик затлар белән югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре, фәнни оешмалар арасында төзелгән шартнамәләр нигезендә физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

### 34 статья. Физик культура һәм спорт өлкәсендә ихтыярый нигездә эш алып баручы оештыручылар

Физик культура һәм спорт өлкәсендә ихтыярый нигездә эш алып баручы оештыручылар - спорт төрләре буенча физкультура оештыручылары, инструкторлары, эш урыны гимнастикасы, туризм һәм альпинизм инструкторлары, спорт судьялары һәм физкультура-спорт оешмаларының, спорт клубларының идарә әгъзалары, төрле спорт төрләре буенча секцияләрнең бюро әгъзалары һәм физик культура коллективлары советлары әгъзалары, физик культура һәм спорт өлкәсендә ихтыярый нигездә эш алып баручы бүтән оештыручылар.

Әлеге статьяның беренче абзацында күрсәтелгән затларны әзерләү, аларны яңадан әзерләү һәм аттестацияләү Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Спорт ярышларына судьялык итүгә махсус әзерлек узган һәм физкультура-спорт оешмаларында аттестацияләнгән спорт судьялары җәлеп ителә.

35 статья. Спортчыларны һәм физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләрен социаль яклау

Төрле спорт төрләре буенча Татарстан Республикасынын жыелма командалары составына керүче спортчылар, төрле спорт төрләре буенча Россия Федерациясе яисә СССР жыелма командалары составына кергән спортчылар, шулай ук физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге законнар нигезендә социаль яклану хокукына ия.

VI бүлек. Физкультура һәм спорт өлкәсендә ресурс тәэминаты

36 статья. Физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалар төзү һәм аларны тоту

1. Физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалар федераль, республика һәм жирле әһәмияттәге корылмаларга бүленә һәм дәүләт идарәсенең тиешле органнарына, жирле үзидарә органнарына, физкультура-спорт оешмаларына, башка оешмаларга, шулай ук физик затларга карарга мөмкин.

Физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалар күрсәтелгән затларның үз акчалары исәбеннән төзелгән яисә сатып алынган булсалар, физик затлар карамагында булырга мөмкин.

Дәүләт хакимияте органнары төзегән физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалар (шул исәптән төрле спорт төрләре буенча Татарстан Республикасынын жыелма командаларына үзәкләштерелгән әзерлекне тәэмин итүче, дәүләт милкендәге спорт корылмалары) һәм алар били торган жир кишәрлекләре хосусыйлаштырылырга тиеш түгел.

Физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмаларын физкультура- массакүләм һәм спорт буенча гражданнар белән эшләү өчен файдаланыла торган корылмаларга кертү, салым салу мәсьәләләре һәм бүтән түләүләр буенча ташламалар бирү Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, жирле

үзидарә органнары тарафыннан тиешле физкультура-спорт оешмалары күрсәтмәсе буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

2. Дәүләт физкультура-савыктыру, спорт-техник корылмаларын төзүне, реконструкцияләүне һәм файдалануны финанслауда катнаша, шартнамәләр шартларында аларны төзүгә һәм тотуга башка оешмаларны җәлеп итә.

3. Физкультура-савыктыру һәм спорт корылмалары булмыйча, барлык типтагы дәүләт мәгариф учреждениеләрен төзү һәм булганнарын реконструкцияләү рөхсәт ителми, шулай ук дәүләт милкендәге яисә жирле үзидарә милкендәге гамәлдәге спорт корылмаларын бетерү әлеге территориядә шуңа тиң корылма булдырылганчы рөхсәт ителми.

4. Торак районнарны төп физкультура-спорт корылмалары белән тәэмин итү нормативлары Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы тарафыннан шәһәр төзелеше нормалары нигезендә билгеләнә.

5. Гражданнарның яшәү урыны буенча физкультура-савыктыру һәм спорт корылмаларын тоту, шул исәптән мондый корылмаларны ремонтлау, массакүләм спорт гамәлләрен оештыру, районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районарның халкы белән шөгыльләнүче физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шәһәрләрнең, районнарның һәм шәһәрләрдәге районнарның жирле администрацияләре һәм жирле үзидарә органнары актларында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Күрсәтелгән гамәлләр шулай ук районнарны һәм шәһәрләрне үстерү буенча бюджеттан тыш фондлар, үз спорт корылмалары булмаган оешмаларның, физик затларның ихтыярый кертемнәре һәм закон белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән финансланырга мөмкин.

6. Физик культура һәм спорт өлкәсендә урта һөнәри, югары һөнәри мәгариф учреждениеләренә һәм фәнни оешмаларга, югары спорт мастерлыгы мәктәпләренә, олимпия әзерлеге үзәкләренә, олимпия резервы училищеларына, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләренә һәм башка спорт мәктәпләренә оператив идарә итү хокукында биналар, спорт корылмалары, социаль, мәдәни, бүтән максаттагы мөлкәт , жиһазлар һәм башка кирәкле мөлкәт даими

(озак вакытка) файдалану өчен аларга һәм физкультура-савыктыру һәм спорт-техник корылмалар биләүчеләренә жир турындагы законнар нигезендә бүлеп бирелгән жир кишәрлекләре беркетелә.

7. Физкультура-савыктыру оешмаларына, барлык типтагы спорт мәктәпләренә, олимпия резервы училищеларына, физик культура һәм спорт өлкәсендәге мәгариф учреждениеләренә һәм фәнни оешмаларга, спорт корылмаларына, кайсы ведомствога карауларына һәм нинди милек рәвешендә булуларына бәйсез рәвештә спорт сәнәгасе предприятиеләренә газ челтәре, электр, җылылык энергиясе, су тәэминаты һәм суүткәрү тарифлары халыкка күрсәтелгән ресурсларны җибәрү өчен каралган тәртиптә һәм почта, телеграф, телефон элемтәсе хезмәтләреннән файдалану тарифлары бюджет оешмалары өчен билгеләнгән рәвештә кагыла.

8. Спорт корылмаларыннан, бары тик турыдан-туры билгеләнешендә генә, мәдәни һәм бүтән спорт-тамаша гамәлләре үткәрүгә бәйле максатларда гына файдалану рөхсәт ителә. Физкультура-савыктыру һәм спорт корылмалары биналарын һәм мәйданнарын арендага бирүдән алына торган һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә төп эшчәнлекне башкарганда файдаланылмый торган акчалары үз балансындагы оешмалар тарафыннан бары тик спорт мәктәпләрендә һәм физкультура-савыктыру төркемнәрендә дәресләр оештыруга һәм үткәрүгә, мондый физкультура-савыктыру һәм спорт корылмаларын тотуга, ремонтлауга һәм үстерүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен генә тотылалар.

9. Төрле спорт төрләре буенча Татарстан Республикасының җыелма командаларын әзерләү максатларында Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән яисә закон белән тыелмаган бүтән чыганаклар исәбеннән төзелгән республика әһәмиятендәге спорт корылмалары оператив идарә итүгә Татарстан Республикасының җыелма командаларын бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларына әзерләү буенча дәүләт функцияләрен башкаручы һәм әлеге максатларда Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән акчалар алучы Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органына беркетелергә мөмкин. Мондый корылмаларны оператив

идарә итүгә беркетү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителә.

10. Төрле спорт төрләре буенча Татарстан Республикасының җыелма командаларын әзерләү алып барыла торган спорт базалары өчен әлеге статьяның 7 пункты нигезендә аларны тотуда ташламалы шартлар билгеләнә. Мондый базаларның исемлеге Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы күрсәтмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Республика милкендәге һәм оператив идарә итүгә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органына беркетелгән спорт базалары Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән һәм закон белән тыелмаган бүтән чыганаклар исәбеннән финанслана.

11. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары спорт ярышларына йөрү, үз милкендәге спорт корылмаларын арендалау , гражданнарга мондый корылмалардан файдалану өчен абонементлар сату, мондый спорт корылмаларында мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен, аз керемле һәм күп балалары гаиләләрнең балалары өчен, шулай ук мәгариф учреждениеләрендә укучылар, пенсионерлар, инвалидлар өчен түләүсез яисә ташламалы шартларда дәресләр үткәрергә рөхсәт бирергә һәм кирәк булган очракта тиешле бюджетлар яисә закон белән тыелмаган бүтән чыганаклар исәбеннән компенсацияләр карарга мөмкин.

37 статья. Физик культура һәм спорт дәресләре үткәргәндә, спорт ярышларын һәм физкультура-спорт тамашалары гамәлләрен үткәргәндә гражданнарның хәвефсезлек кагыйдәләрен, сәламәтлекләрен, намусын һәм абруен саклау

Физкультура-савыктыру оешмалары хезмәткәрләре физик культура һәм спорт дәресләре, спорт ярышлары һәм физкультура-спорт тамашалары гамәлләрен үткәргәндә хәвефсезлек нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәргә тиеш, гражданнарның сәламәтлегенә, намусына

һәм абруена зыян китерүгә, рәхимсезлек һәм көч куллану чагылышларына юл куймаска тиеш.

Физкультура-савыктыру һәм спорт корылмаларының урындагы затлары спорт дәресләрен һәм ярышларын үткәрү урыннарын техника куркынычсызлыгы һәм санитария-гигиена нормалары нигезендә тиешенчә техник җиһазлауны тәэмин итә һәм физик культура, спорт дәресләре, спорт ярышлары һәм физкультура-спорт тамашалары гамәлләре үткәргәндә законнар нигезендә җаваплы булалар.

38 статья. Спорт сәнәгасе

Дәүләт Татарстан Республикасы спорт сәнәгасе үсешенә (шул исәптән спорт сәнәгасенең яңа предприятиеләрен төзүгә һәм гамәлдәге предприятиеләрне яңартуга) төрле дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт үсеше) программалары нигезендә ярдәм итә.

39 статья. Физик культура һәм спорт өлкәсендә салым салу

1. Савыктыру, массакүләм физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне башкаручы барлык милек рәвешләрендәге физкультура-спорт оешмалары, спорт корылмалары салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым салулардан, түләүләрдән һәм җыемнардан, шул исәптән хезмәт һәм табигать ресурсларыннан, су объектларыннан файдалану өлкәсендә дә, азат ителергә мөмкин.

Гражданнарның физик тәрбия ихтыяжларына, төрле спорт төрләре буенча спорт командаларын, Татарстан Республикасынын җыелма командаларын тоту өчен оешмаларнын һәм спонсорларнын махсус счетларга күчерелә һәм әлеге берләшмәләрнен устав максатларында файдаланыла торган акчалары, шулай ук физкультура-спорт берләшмәләренең эшкуарлык эшчәнлеге керемнәре (моңа акцизлы товарларны таможня территориясенә кертү, житештерү һәм реализацияләү керми) законнар нигезендә салым салынудан азат ителергә мөмкин.

2. Физик затларга салым салынганда салым салына торган җыелма керемгә түбәндәгеләр керми:

туклану, спорт җиһазы, җайланмасы, спорт һәм спортчылар һәм физкультура-спорт хезмәткәрләре тарафыннан укыту-күнекмәләр процессында һәм спорт ярышларында катнашу өчен алынган спорт һәм парад киеме;

спортчылар тарафыннан Олимпия уеннарында, дөнья һәм Европа чемпионатларында һәм кубокларында беренче һәм призлы урыннар яулаган өчен күрсәтелгән спорт ярышларын оештыручылардан Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә алына торган, Россия Федерациясе чемпионатларында һәм кубокларында әлеге спорт ярышларын оештыручылардан алына торган премияләр һәм призлар (акчалата һәм әйберләтә);

спортчылар тарафыннан Олимпия уеннарында, дөнья һәм Европа чемпионатларында һәм кубокларында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы чемпионатларында һәм кубокларында әлеге спорт ярышларын оештыручылардан ала торган премияләр һәм призлар (акчалата һәм әйберләтә). Әлеге ташлама салымның Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә кулланыла.

40 статья. Физкультура-спорт оешмаларының тышкы икътисадый эшчәнлегенә ярдәм итү

Дәүләт идарәсенең республика органнары һәм җирле органнары физкультура-спорт оешмаларына экспорт-импорт гамәлләрен башкаруны, тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендәге программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруны хуплыйлар, мондый оешмаларның халыкара спорт ярышларында һәм спорт-тамаша гамәлләрендә укыту-күнекмәләр җыеннарында катнашуына ярдәм итәләр.

41 статья. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче чит ил гражданнарының һәм гражданлыксыз затларның физик культура һәм спорт өлкәсендәге хокуклары

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар әлеге Законда каралган

күләмдә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү хокукына ия булалар, моңа халыкара ярышларда һәм бөтенроссия ярышларында Татарстан Республикасы җыелма командасы составында чыгыш ясау хокукы керми.

42 статья. Халыкара физкультура һәм спорт оешмаларында катнашу

Татарстан Республикасы территориясендә физик культура һәм спорт өлкәсендә халыкара оешмаларның филиаллары төзелергә мөмкин. Теләсә кайсы юридик яисә физик зат халыкара физкультура һәм спорт оешмасы уставларында билгеләнгән тәртип нигезендә ул оешмаларга керергә хокуклы. Физкультура һәм спорт оешмалары үз сафларына чит ил гражданнарын җәлеп итәргә, шулай ук халыкара оешмалардан, чит дәүләтләрдән һәм хосусый затлардан алынган максатчан акчалар белән мөстәкыйль эш итәргә хокуклы.

VII бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

43 статья. Әлеге Законны бозган өчен урындагы затларның җаваплылыгы

Әлеге Законны бозган өчен урындагы затлар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

44 статья. Норматив хокукый актларны әлеге Законга туры китерү

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерүне йөкләргә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына 2000 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча дәүләт программасын әлеге Закон нигезләмәләренә туры китерү

164



турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертүне йөкләргә.

45 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү

Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2476